ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 647 2017 елның 18 октябре

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы халкын янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә әзерләү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешү нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы халкын янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә әзерләү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә

1.1. Карарның 2 пунктында «авыл җирлекләре башлыкларына һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Карарны түбәндәге редакциядә 3, 4 пунктлары белән тулыландырырга:

«3. Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлекләре һәм Кама Аланы штп башкарма комитетларына җирлекләр халкын янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә әзерләү тәртибен раслый торган шундый муниципаль хокукый актлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

«4. Әлеге карар белән раслана торган тәртипнең гамәлдә булуы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенә кагыла дип билгеләргә».

1.3. Карарның 3, 4 пунктларын 5, 6 пунктлар дип санарга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары Р.Ә. Хаҗиев